ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.05.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1353**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 декабрендәге 2586 номерлы карары белән расланган «2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа»га үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» 2022 елның 15 декабрендәге 224 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 декабрендәге 2586 номерлы карары белән (2022 елның 08 ноябрендәге 3060 номерлы , 2023 елның 13 сентябрендәге 2779 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа»га түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 «Программа паспорты» 1 нче бүлегендә «Программа күләме һәм финанслау чыганаклары мең сум» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары (мең сум) | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 9 182,738 | 11 121,148 | 14 716,632 | 13 621,597 | 12 833,820 | 61 475,935 |
| | Федераль бюджет чаралары | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Республика бюджеты чаралары | 4 016,200 | 4 335, 602 | 4 525,400 | 4 859,0 | 4 997,2 | 22 733,402 |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 13 198, 938 | 15 456, 750 | 19 242,032 | 18 480,597 | 17 831,020 | 84 209,337 |

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итү» 4 нче бүлегендә:

1.2.1 беренче абзацны һәм таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Программаның гамәлдә булган барлык чорында гамәлгә ашыруга якынча чыгымнар 84 209,337 мең сум тәшкил итә, шул исәптән (мең сум).

| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Федераль бюджет чаралары | - | - | - | - | - |
| Республика бюджеты чаралары | 4 016,200 | 4 335,602 | 4 525,400 | 4 859,0 | 4 997,2 |
| Муниципаль бюджет | 9 182,738 | 11 121,148 | 14 716,632 | 13 621,597 | 12 833,820 |
| Барлыгы: | **84 209,337** | | | | |

1.3. « Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» 9 нчы бүлекне, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

1.4. «Программа бүлекләре буенча финанс чараларын исәпләү» 1 нче кушымтаны, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

ЗМР Башкарма комитетының
2024 елның 22 маендагы
1353 номерлы карарына
1нче кушымта

**9. Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау**

| Максат: Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 нче бурыч. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүе | | | | | | | |
| Индикатор күрсәткечләре | | | | | | | |
| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | 2019 ел (база елы) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Кылган җинаятьләр саны, берәмлекләр | | 2341 | 2235 | 2178 | 2084 | 1996 | 1835 |
| Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | **Финанслау, мең сум.** | | | | |
| | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1.1. Халыкта законсыз саклаган корал һәм сугыш кирәк-яракларын ирекле тапшыруны стимуллаштырырга.<br>1.1.1 Иҗтимагый урыннарда агитация-реклама материалларын әзерләү һәм урнаштыру | Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча)<br><br>ЗМР БК | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 1.2. Коррупциягә каршы көрәш, ялган акча, алкоголь һәм спиртлы продукциянең законсыз әйләнеше буенча оператив-профилактик | Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| чаралар үткәрергә, аларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртырга.<br>1.2.1 агитация-реклама материаллары әзерләү һәм аларны җәмәгать урыннарында урнаштыру | буенча) , Дәүләт алкоголь инспекциясе (килешү буенча), ММЧ ЗМР БК | | | | | | |
| 1.3. Хокук бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән пиар-акцияләр оештырырга, аларның барышын һәм нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртырга | ЗМР БК, ММЧ | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 1.4. Контроль буенча үткәрелә торган планлы чаралар кысаларында психоактив матдәләр булган продукцияне ачыклау һәм әйләнештән алу буенча чаралар үткәрү. | ЗМР БК, ЭЭМБ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 1.5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә тәмәке әйберләрен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы эшкуарлыкның хуҗалык субъектларын, билгеләнгән таләпләрне бозып тәмәке әйберләрен сату фактларын ачыклап, контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | ЗМР БК , ЭЭМБ (килешү буенча) | 2021 – 2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 1.6. Алкогольле һәм спиртлы продукциянең - легаль булмаган әйләнешен, балигъ булмаганга тәмәке әйберләрен, алкогольле һәм спиртлы продукцияне сату фактларын булдырмауга, контрафакт һәм фальсификацияләнгән товарларны әйләнештән алуга юнәлдерелгән оператив-профилактик чараларны гамәлгә ашыру | Дәүләт алкоголь инспекциясе (килешү буенча), ЭЭМБ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 1.7. Корал, шартлату җайланмалары (стационар металл рамкалары, коймалар һ.б.) кулланып кылына торган җинаятьләрне, | ЗМР БК | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| террорчылык актларын кисәтү һәм булдырмау буенча муниципаль учреждениеләргә керү урынында урнаштыру өчен билгеләнгән махсус җиһазлар сатып алу. | | | | | | | |
| 1.8. Полиция территориаль бүлекләрен һәм тәртип саклау җәмәгать пунктларын ремонтлау һәм җиһазлау буенча эшләр оештыру | Җирлекләр администрациясе, Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| Максат: Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү | | | | | | | |
| 2 нче бурыч. Балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау. | | | | | | | |
| Индикатор күрсәткечләре | | | | | | | |
| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | | 2019 ел (база елы) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күрсәткече, процентларда | | 7,5 | 7,35 | 7,20 | 7,05 | 6,95 | 6,80 |
| Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Финанслау, мең сум. | | | | |
| | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 2.1 Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең еллык слётын һәм уку җыемнарын үткәрү | ЗМР БК, ЗМР КБМҮ, МИ, УДМС | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.2. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре арасында ел саен үткәрелә торган республика конкурсының муниципаль этабын уздыру. | ЗМР БК, ЗМР КДН, МИ. | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3. Тематик лекцияләр, сыйныф сәгатьләре, телетапшырулар үткәрү, яшүсмерләр арасында җинаятьчелек, имин булмаган гаиләләр, балигъ булмаганнарга карата хокукка каршы көрәш, караучысызлык, эчкечелек, наркомания һәм токсикомания, балалар арасында юл-транспорт травматизмы һ. б. проблемалар буенча мәкаләләр бастырып чыгару. | ЗМР БК, ММЧ, ЗЦРБ, ОДМ, ОС, УО, ОСЗ (килешү буенча), ЦЗН (килешү буенча), Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.4. 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны укудан һәм каникуллардан буш вакытларында эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү. | ЦЗН(мәшгульлек үзәге (килешү буенча), МИ | 2021-2025 еллар | 387,933 (ЗМР бюджеты) | 588,268 (ЗМР бюджеты) | 157,538 (ЗМР бюджеты) | - | - |
| 2.5. Яшьләр һәм яшүсмерләр арасында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау мәсьәләләрендәге уңышлары өчен югары, урта һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре студентлары һәм укучыларын ЗМР Башлыгының махсус стипендиясе белән бүләкләү. | ЗМР БК, ОДМ, ОС, С, ОМВД (килешү буенча), УО, "Форпост" ЗЦ | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.6. Зеленодольск муниципаль районы уку йортларында мәктәп профилактикасы отрядлары челтәрен алга таба киңәйтү, аларның матди-техник базасын ныгыту буенча чаралар үткәрү. | МИ, ЭЭМБ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.7. «Иң яхшы профилактика отряды» конкурсын үткәрү (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә, эчке эшләр бүлегенең ОПДН инспекторларының уку йортларында | МИ, ЭЭМБ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| профилактика отрядлары белән эшен оештыруда ярдәм күрсәтү). | | | | | | | |
| 2.8. Галимнәрне, практикларны, хакимият органнары вәкилләрен, хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итеп хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация күтәрү курслары, төрле фәнни-гамәли чаралар үткәрү. | ЗМР БК, КДН, ЗМР, УО, ОДМ, ОС, ЭЭМБ (килешү буенча), ОСЗ (килешү буенча), ЦЗН (килешү буенча), ЗЦРБ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.9. Махсуслаштырылган лицей, мәктәп һәм класс (юридик, кадет, яшь коткаручылар, автокласслар һ.б.) укучылары белән спартакиадалар, ярышлар, конкурслар, «Куркынычсызлык мәктәбе», «Батырлык һәм хокук тәрбиясе дәресләре» үткәрү. | ЗМР БК, УО, ОДМ, ОСЗ (килешү буенча), ЗЦРБ (килешү буенча), Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (килешү буенча), ГВК (килешү буенча), ОМВД (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.10. Гамәлдәге полиция һәм кадет сыйныфлары эшчәнлегенә ярдәм итү һәм алга таба үстерү. | ЗМР БК,МИ, ЗМР КДН , ОДМ, ОС, МЧС (килешү буенча), ГВК (килешү | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | буенча), ОМВД (килешү буенча) | | | | | | |
| 2.11. Социаль куркыныч хәлдә булган балалар, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен сәламәтләндерү лагерьларында, физкультура-ял һәм спорт учреждениеләрендә бушлай урыннар квоталауны оештыру. | ЗМР БК, МИ, ЗМР КДН, ОДМ, ОС | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.12. Хокук бозуларны профилактикалау буенча тематик кино-видео-фильмнар алу һәм аларны кино-дәресләр (кинолекторийлар) уздырганда күрсәтү , мәктәп , урта һәм югары уку йортлары укучыларында хокукый аң формалаштыру, идея-әхлакый тәрбияләү. | ЗМР БК | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.13. Чакырылышка кадәрге яшьләр, шул исәптән Зеленодольск районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгында исәптә торучы затлар арасында ел саен үткәрелә торган спартакиада;<br>ел саен үткәрелә торган «Алга, яшь армиячеләр» хәрби-патриотик уены;<br>яшьләр өчен хәрби-спорт, патриотик чатыр җыеннары, интеллектуаль уеннар һәм спортның уен төрләре буенча чемпионатлар үткәрү, шул исәптән Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлегенең профилактик исәбендә торучы затлар катнашында. | ЗМР БК, МИ, ЗМР КДН , ОДМ, ОС, ГВК (килешү буенча), ОМВД (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.14. Хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге әзерлек үзәкләрендә белем алучы чакырылыш яшендәге гражданнарга тыл хезмәтчәннәре, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш | ЗМР БК, МИ, ЗМР КДН , ОДМ, ОС, ГВК | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| хәрәкәтләрендә һәм локаль конфликтларда катнашучылар, ДОСААФ вәкилләре белән очрашулар; җинаятьләрне һәм социаль-тискәре күренешләрне профилактикалау буенча фәнни-гамәли конференцияләр үткәрү. | (килешү буенча), ЭЭМБ (килешү буенча) | | | | | | |
| 2.15. Техник иҗат клублары, картинг-клублар (секцияләр), авто-, мотоклублар эшен оештыру. | ЗМР БК, ОДМ, ОС, | 2021-2025 еллар | | | | | |
| 2.16. Яшүсмерләр өчен, шул исәптән Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлегендә исәптә торучылар өчен, туристик походлар, профильле хәрби-патриотик сменалар оештыру. | ОДМ, ОС, ЗМР КДН . | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.17. Мәгариф объектларын, шул исәптән мәктәпкәчә, гомуми, өстәмә белем бирү учреждениеләрен, шулай ук ведомстводан тыш саклау бүлекчәләренең үзәкләштерелгән саклау пунктлары эшчәнлеге зонасында урнашкан балалар сәламәтләндерү лагерьларын җинаятьчелеккә каршы куркынычсызлык һәм саклауның техник системалары белән җиһазландыру. | ЗМР БК , МИ, ОДМ, ОС | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.18. Тәрбия өлкәсендә кадрларның квалификациясен күтәрү курслары кысаларында яшүсмерләр-яшьләр арасында экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча белем бирү модулен гамәлгә ашыру. | МИ, ОДМ, ОС | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.19. Яшүсмерләр һәм яшьләр белән мәдәниятара һәм конфессияара диалогны үстерү буенча чаралар комплексын (слетлар, конференцияләр, семинарлар, форумнар, психологик һәм коммуникатив тренинглар) үткәрү, толерант тәртип күнекмәләренә өйрәтү. | ОДМ, ОС, МИ | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

<table>
<tr><td colspan="8">Максат: Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү</td></tr>
<tr><td colspan="8">3 нче бурыч. Хөкем ителүчеләрне иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру</td></tr>
<tr><td colspan="8">Индикатор күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td colspan="2">Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре</td><td>2019 ел (база елы)</td><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>2024 ел</td><td>2025 ел</td></tr>
<tr><td colspan="2">Тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында элек җинаять кылган затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күрсәткече, процентларда</td><td>40,9</td><td>39,5</td><td>38,7</td><td>37,6</td><td>35,9</td><td>34,1</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Төп чараларның исемнәре</td><td rowspan="2">Башкаручылар</td><td rowspan="2">Төп чараларны башкару сроклары</td><td colspan="5">Финанслау, мең сум.</td></tr>
<tr><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>2024 ел</td><td>2025 ел</td></tr>
<tr><td>3.1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга документларны торгызуда һәм рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү.</td><td>ЗМР БК , ЭЭМБ (килешү буенча)</td><td>2021-2025 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>3.2. Иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгәннәр өчен медицина тикшерүе үткәрүне оештыру, шулай ук туберкулез белән авыручылар өчен дәвалау-диагностика чараларын үткәрү.</td><td>ЗЦРБ (килешү буенча КУ ИК– 5(килешү буенча) , УФСИН (килешү буенча)</td><td>2021-2025 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>3.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү, шул исәптән резервланган эш урыннарына.</td><td>ЗМР БК, ЦЗН (килешү буенча)</td><td>2021-2025 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>3.4. Халыкны эш белән тәэмин итү мобиль үзәген җәлеп итеп, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 5 нче төзәтү колониясендә «Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте көне» дигән күчмә һөнәри юнәлеш бирә торган</td><td>ЦЗН (килешү буенча)</td><td>2021-2025 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td>чаралар уздыру.</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="8">Максат: Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү</td></tr>
<tr><td colspan="8">4 нче бурыч. Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлеген оештыру һәм җәмәгать урыннарында хокук тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм җинаятьләрне ачу өчен заманча техник чаралар кертү</td></tr>
<tr><td colspan="8">Индикатор күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td colspan="2">Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре</td><td>2019 ел (база елы)</td><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>2024 ел</td><td>2025 ел</td></tr>
<tr><td colspan="2">Теркәлгән җинаятьләрнең гомуми санынннан җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күрсәткече, процентларда</td><td>34,5</td><td>34,0</td><td>33,4</td><td>32,6</td><td>31,8</td><td>31,1</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Төп чараларның исемнәре</td><td rowspan="2">Башкаручылар</td><td rowspan="2">Төп чараларны башкару сроклары</td><td colspan="5">Финанслау, мең сум.</td></tr>
<tr><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>2024 ел</td><td>2025 ел</td></tr>
<tr><td>4.1. Зеленодольск муниципаль районында гражданнар күпләп була торган урыннарда, муниципаль учреждениеләрдә һәм оешмаларда видеоконтроль системасын модернизацияләү һәм үстерү.</td><td>ЗМР БК</td><td>2021 - 2025 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>4.2. «Имин шәһәр» видеокүзәтү системасын финанслауны тәэмин итү.</td><td>ЗМР БК</td><td>2021-2025 еллар</td><td></td><td>1 284,944 (ЗМР бюджеты)</td><td>1 498,910 (ЗМР бюджеты)</td><td>1 284,944 (ЗМР бюджеты)</td><td></td></tr>
<tr><td>4.3. Белем бирү учреждениеләрендә лекцияләр һәм әңгәмәләр уздырганда, җәмәгать транспортында, халык күпләп ял итә торган урыннарда куллану максатыннан, хокук бозуларны профилактикалау буенча методик материаллар, буклетлар, мәгълүмати листовкалар, стикерлар, баннерлар, плакатлар әзерләү.</td><td>ЗМР БК , ЭЭМБ (килешү буенча)</td><td>2021-2025 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>4.4. Полиция участок уполномоченныйлары</td><td>ЗМР БК</td><td>2021-2025</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| вазыйфасын биләүче хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына, хезмәткәрләрнең күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларын үтәү чорында, торак урыннары бирү. | | еллар | | | | | |
| 4.5. Россия Федерациясе территориясендә легаль булмаган чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны, шул исәптән хезмәт эшчәнлеген законсыз гамәлгә ашыручы затларны ачыклау буенча уртак оператив-профилактик чаралар үткәрү. | УФСБ (килешү буенча), ОМВД (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 4.6. Россия Федерациясендә чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан хокук бозуларны профилактикалау һәм аларның хокукый хәле, шул исәптән вакытлыча яшәүгә рөхсәтнамә яисә яшәүгә рөхсәт рәсмиләштерү, Россия Федерациясе гражданлыгын алу мәсьәләләре буенча ММЧда аңлату эше алып бару. | ММЧ, ЭЭМБ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 4.7. Җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә, яшүсмерләргә һәм яшьләргә хокукый тәрбия бирүгә өлеш керткән предприятиеләр һәм оешмалар, уку йортлары һәм физик затлар арасында ел саен үткәрелә торган «Закон территориясе» республика конкурсының муниципаль этабын уздыру. | ЗМР БК | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 4.8. «Иң яхшы авыл участок уполномоченные», «Һөнәре буенча иң яхшы», «Иң яхшы тәртип саклау җәмәгать пункты» һәм «Иң яхшы җәмәгать тәртибен саклау пункты җитәкчесе» исемнәренә ел саен , җиңүчеләрне премияләп, һөнәри осталык бәйгеләрен үткәрү. | ЗМР БК , ЭЭМБ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

<table>
<tr><td>4.9 Зеленодольск муниципаль районында хокук саклау терәк пунктлары хезмәткәрләренең эшчәнлеген финанслау<br>4.9.1 Шәһәр җирлекләренең хокук-тәртип саклау терәк пунктлары хезмәткәрләре эшчәнлеген финанслау</td><td>ЗМР БК</td><td>2021 – 2025 Еллар</td><td>8 764,219 (ЗМР бюджеты)<br>Шул исәптән 548,862 (шәһәр җирлекләре акчалары)</td><td>9206,555 (ЗМР бюджеты) 278,702 (ТР чаралары)<br>Шул исәптән 548,864 (шәһәр җирлекләре акчалары)</td><td>12 977,424 (ЗМР бюджеты)<br>Шул исәптән 682,474 (шәһәр җирлекләре акчалары)</td><td>12 336,653 (ЗМР бюджеты)<br>Шул исәптән 689,301 (шәһәр җирлекләре акчалары)</td><td>12 833,820 (ЗМР бюджеты)<br>Шул исәптән 717,080 (шәһәр җирлекләре акчалары)</td></tr>
<tr><td colspan="8">Максат: Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү</td></tr>
<tr><td colspan="8">5 нче бурыч: Урамнарда хокук тәртибен тәэмин итү</td></tr>
<tr><td colspan="8">Индикатор күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td colspan="2">Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре</td><td>2019 ел (база елы)</td><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>2024 ел</td><td>2025 ел</td></tr>
<tr><td colspan="2">Теркәлгән җинаятьләрнең гомуми санынннан урамнарда кылынган җинаятьләрнең чагыштырмача күрсәткече, процентлар</td><td>22,7</td><td>21,9</td><td>21,2</td><td>20,8</td><td>20,3</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Төп чараларның исемнәре</td><td rowspan="2">Башкаручылар</td><td rowspan="2">Төп чараларны башкару сроклары</td><td colspan="5">Финанслау, мең сум.</td></tr>
<tr><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>2024 ел</td><td>2025 ел</td></tr>
<tr><td>5.1. Гражданнарны ирекле халык дружиналарына җәлеп итү, яшьләр хокук саклау хәрәкәтен үстерү, шул исәптән студентлар һәм эшче яшьләрне, шулай ук полициянең штаттан тыш хезмәткәрләре институтын үстерү буенча чаралар үткәрү.</td><td>ЗМР БК , ЭЭМБ (килешү буенча)</td><td>2021-2025 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>5.2. Массакүләм мәгълүмат чараларында җәмәгать тәртибен саклауда ирекле катнашучы затларның уңай эш тәҗрибәсен һәм фидакарь гамәлләрен пропагандалауны гамәлгә ашыру.</td><td>ММЧ, ЭЭМБ (килешү буенча)</td><td>2021-2025 еллар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>5.3. Җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы</td><td>ЗМР БК ,</td><td>2021-2025</td><td>30,586 (ЗМР</td><td>41,381 (ЗМР</td><td>82,760 (ЗМР</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| халык дружиначыларын матди кызыксындыру. | ЭЭМБ (килешү буенча) | еллар | бюджеты) | бюджеты) | бюджеты) | | |
| 5.4. Җәмәгать тәртибен саклау буенча ел саен үткәрелә торган спартакиадалар, чемпионатлар, беренчелекләр, хәрби-кыр җыеннары, яшьләр (эшчеләр), мәктәп һәм студентлар формированиеләренең слетларын һәм конференцияләрен үткәрү. | ОДМ, ОС, УО, "Форпост" ЗЦ, ОМВД (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 5.5. «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, студентлар һәм мәктәп формированиеләре үзәге» МБУ матди-техник базасын ныгыту, шул исәптән кием-салым, оргтехника, элемтә чаралары һәм спорт инвентарьлары белән тәэмин итү. | ЗМР БК | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 5.6. Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, студентлар һәм мәктәп формированиеләре әгъзалары өчен сәламәтләндерү лагерьларында ел саен профильле сменалар оештыру. | ОДМ, ОС, УО, "Форпост" ЗЦ, ОМВД (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 5.7. Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (эшчеләр), мәктәп һәм студентлар формированиеләренең, халык дружиналарының һәм полициянең штаттан тыш хезмәткәрләренең еллык укыту-методик җыелышларын үткәрү. | ЗМР БК, ОДМ, ОС, УО, "Форпост" ЗЦ, ОМВД (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |
| 5.8. Массакүләм чаралар үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүгә җәмәгатьчелек көчләрен (ЧЖО, ДНД, полициянең штаттан тыш хезмәткәрләрен, яшьләр иҗтимагый оешмаларын) гражданнар | ЗМР БК, ЭЭМБ (килешү буенча) | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| күпләп ял итә торган урыннарда җәлеп итү. | | | | | | | |
| 5.9. ЗМР территориясендә «Айныткыч» МКСУ эшчәнлеген тәэмин итү | ЗМР БК | 2021-2025 еллар | 4 016,200 (Республика бюджеты чаралары) | 4 056,900 (Республика бюджеты акчалары) | 4 525,400 (Республика бюджеты чаралары) | 4 859,0 (Республика бюджеты чаралары) | 4 997,200 (Республика бюджеты чаралары) |

ЗМР Башкарма комитетының
2024 елның 22 маендагы
1353 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Программа бүлекләре буенча финанс чараларын исәпләү**

| Программа пунктлары | Финанслау, мең сумнарда | | | | | Чара нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | |
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүе | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау. | 387,933 (ЗМР бюджеты) | 588,268 (ЗМР бюджеты) | 157,538 (ЗМР бюджеты) | 0 | 0 | 1 133,739 (ЗМР бюджеты) |
| Хөкем ителүчеләрне иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Җәмәгать иминлеген тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлеген оештыру һәм җәмәгать урыннарында хокук тәртибен һәм иминлеген тәэмин итү һәм җинаятьләрне ачу өчен заманча техник чаралар кертү. | 8 764,219 (ЗМР бюджеты) | 10 491,499 (ЗМР бюджеты)<br>278,702 (ТР чаралары) | 14 476,334 (ЗМР бюджеты) | 13 621,597 (ЗМР бюджеты) | 12 833,820 (ЗМР бюджеты) | 60 187,469 (ЗМР бюджеты)<br>278,702 (ТР чаралары) |
| Урамнарда хокук тәртибен тәэмин итү | 30,586 (ЗМР бюджеты) 4 016,200 (Республика бюджеты чаралары) | 41,381 (ЗМР бюджеты) 4 056,900 (Республика бюджеты акчалары) | 82,760 (ЗМР бюджеты) 4 525,400 (Республика бюджеты чаралары) | 4 859,0 (Республика бюджеты чаралары) | 4 997,200 (Республика бюджеты чаралары | 154,727 (ЗМР бюджеты) 22 454,700 (Республика бюджеты чаралары) |
| БАРЛЫГЫ | 13 198,938 | 15 456,750 | 19 242,032 | 18 480,597 | 17 831,020 | 84 209,337 |